| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

---

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>21.03.2026 | Буа шәһәре | **КАРАР**<br>99/Б/к |

«Опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека, попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын башкарудан азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында (суд тәртибендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булмаган затларга карата)» 2022 елның 16 июнендәге 156/Бк/к номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (гамәлдәге редакциядә) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турындагы тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә

1. «Опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека, попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын башкарудан азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында (суд тәртибендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булмаган затларга карата)» 2022:

1.1. 2.4 пункттагы беренче абзацта «15 көн дәвамында» сүзләрен «10 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 3.5.4 пунктының 2, 4 абзацларында «3 көн дәвамында» сүзләрен «2 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.5.3 пунктының 3 абзацында «7 көн дәвамында» сүзләрен «6 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 3.5.2 пунктның 4 абзацында беренче абзацта «3 көн дәвамында» сүзләрен «2 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

1.5.3.5.1 пунктның 3 абзацында беренче абзацта «7 көн дәвамында» сүзләрен «6 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Хәмидуллинга йөкләргә.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Л.Р.Шакирҗанов